| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЛЕБЕДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЕДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** | с. Лебедино | **КАРАР**

28.07.2023 | № 47

**Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Советының 25.04.2013 ел, № 89 «Татарстан Республикасы Алексеевск Муниципаль районы Лебедино авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» Карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып,2023 елның 21 июлендәге ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен (тәкъдимнәрен) исәпкә алып,

**Лебедино авыл җирлеге Советы карар итте:**

1.Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Советының 25.04.2013 ел, № 89 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешалып бару Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында үзгәртергә:

- Лебедино авылының төньяк-көнбатыш өлешендә,аерым алганда түбәндәге адрес буенча:Россия Федерациясе,Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципальрайоны, Лебедино авыл җирлеге, Лебедино авылы, Заречная урамы, Р1 территориаль зонасының өлеше (гомуми файдаланудагы үзе чыккан агачлар һәм ачык яр буе территорияләре )Ж1 территориаль зонасына алмаштырылды (шәхси торак төзелеше зонасы). Территориаль зонаның үзгәртелгән өлешенең гомуми мәйданы 0,6 гектар тәшкил итә.

Әлеге территориаль зонаның урнашу кадастры кварталы: 16:05: 100101.

- Лебединое авылыннан көньяк-көнчыгыш өлештә, аерым алганда түбәндәге адрес буенча:Россия Федерациясе,Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципальрайоны, Лебедино авыл җирлеге,СХ1 территориаль зонасының өлеше

(авыл хуҗалыгы биләмәләре җирләре зонасы) ТПЗ территориаль зонасына алмаштырылды (файдалы казылмалар чыгару өчен билгеләнгән территорияләр). Территориаль зонаның үзгәртелгән өлешенең гомуми мәйданы 32 гектар тәшкил итә.

Әлеге территориаль зонаның урнашу кадастры кварталы: 16:05: 101001.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматларының рәсми порталында урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмати стендта халыкка җиткерергә.

3. Карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **Ю.И. Тюкарев**

Лебедино авыл җирлеге
Советының 28.07.2023 ел,№ 47
карарына 1 нче кушымта

**Карта градостроительного зонирования территории Лебединского сельского поселения Алексеевского муниципального района**

